ГЛАВА
СРЕДНЕТИГАНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АЛЕКСЕЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АЛЕКСЕЕВСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
УРТА ТИГӘНӘЛЕ АВЫЛ
БАШЛЫГЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

02.12.2021 № 6

**«Гражданнарның үзара салым акчаларын
кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча
Алексеевск муниципаль районының
Урта Тигәнәле авыл җирлегенең Түбән Тигәнәле
авылында гражданнар җыенын билгеләү турында»**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 маддәләре, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 маддәсе, Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының Урта Тигәнәле авыл җирлеге Уставы нигезендә

**карар бирәм:**

1. Гражданнар җыенын оештыручы итеп Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының Урта Тигәнәле авыл җирлеге башлыгын билгеләргә.
2. Алексеевск муниципаль районының Урта Тигәнәле авыл җирлегенең Түбән Тигәнәле авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын 2021 елның 18 декабрендә график нигезендә билгеләргә (Кушымта).
3. Гражданнар җыенына чыгарыла торган сорауны расларга:

«Урта Тигәнәле авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 2022 елда үзара салым кертүгә сез, 1 нче төркем инвалидлардан, көндезге уку студентларыннан, Россия Армиясе сафларына ашыгыч хезмәткә чакырылган гражданнардан тыш, 1500 сум күләмендә һәм түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны җибәрү белән килешәсезме:
- авыл эчендәге юлларны төзекләндерү һәм ремонтлау;
- авыл эчендәге юллар төзелеше;
- авыл эчендәге юлларны кышкы һәм җәйге чорда тоту;
- Бөек Ватан сугышында һәлак булган сугышчыларга һәйкәл төзү;
- җирләү урыннарын төзекләндерү;
- су белән тәэмин итү системасын ремонтлау һәм хезмәт күрсәтү.

Аерым мәсьәләләр буенча экономия барлыкка килгән очракта, Урта Тигәнәле авыл җирлеге башкарма комитетына җыенда билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итүгә акча җибәрергә рөхсәт итәргә.

ӘЙЕ ЮК».

4. Әлеге карарны Урта Тигәнәле авыл җирлегенең рәсми сайтында, хокукый мәгълүмат порталында, шулай ук Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының Урта Тигәнәле авыл җирлеге Советы бинасында мәгълүмат стендында бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

5. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

**Алексеевск муниципаль районының**
**Урта Тигәнәле авыл җирлеге башлыгы** **И.К.Хаматвәлиев**

Кушымта

**Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының Урта Тигәнәле авыл җирлегенең Түбән Тигәнәле авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын этаплап уздыру**

**ГРАФИГЫ**

| **Тәртип саны** | **Үткәрү датасы** | **Үткәрү вакыты** | **Үткәрү урыны** | **Урамнарның исеме** |
|---|---|---|---|---|
| **1** | 18.12.2021 | 10.00 | Түбән Тигәнәле АМЙ (Түбән Тигәнәле ав., Үзәк ур., 45 й.) | Яшел ур., Колхоз ур., Тыныч ур., Мәктәп ур. |
| **2** | 18.12.2021 | 13.00 | Түбән Тигәнәле АМЙ (Түбән Тигәнәле ав., Үзәк ур., 45 й.) | Яр буе ур., Күл ур., Кыр ур., Үзәк ур. |